Лельвиж авыл җирлеге Советы

# КАРАР

13 август, 2024 ел №26

Лельвиж авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвижавыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Лельвиж авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Лельвиж авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (2018 елның 07 ноябрендәге 26 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 38 номерлы, 2024 елның 11 июнендәге 16 номерлы үзгәрешләр белән)(алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Айлык акчалата түләү нормативтан артмаган күләмдә түләнә: 11 нче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен – елга 14,12 айлык акчалата түләү 12 нче төркемгә кертелгән муниципаль берәмлек башлыгы өчен – елга 12,86 айлык акчалата бүләкләү.»;

1.2. 3 өлешнең 3.4 пунктчасында «(хезмәттәге катлаулылык, киеренкелек, югары казанышлар, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. түбәндәге эчтәлектәге 3.1 бүлеген өстәргә:

«3.1. Дәүләт бүләге бирү яки бүләкләү өчен бер тапкыр бирелә торган акча

1. Муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, шулай ук бүләкләүгә яисә бүләк бирүгә тәкъдим ителгәннән соң

муниципаль хезмəттəн азат ителгəн Россия Федерациясе гражданнарына (алга таба шулай ук – гражданнар) түбəндəге күлəмдə бер тапкыр бирелə торган акча түлəнə:

а) Татарстан Республикасы Башлыгы (Рəисе), Татарстан Республикасы Дəүлəт Советы Рəисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бүлəклəнгəндə – билəгəн вазыйфасы нигезендə 0,5 вазыйфаи хезмəт хакы (акчалата бүлəклəү) күлəмендə;

б) Татарстан Республикасы Дəүлəт бүлəге белəн бүлəклəгəндə – билəгəн вазыйфасы нигезендə 1,5 вазыйфаи хезмəт хакы (акчалата бүлəклəү) күлəмендə;

в) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмəте тарафыннан бүлəклəнгəндə – бер вазыйфаи хезмəт хакы (акчалата бүлəклəү) күлəмендə;

г) Россия Федерациясенең Дəүлəт бүлəге белəн бүлəклəгəндə – ике вазыйфа оклады (акчалата бүлəклəү) күлəмендə.

2. Бер тапкыр бирелə торган бүлəклəү бүлəклəү яки бүлəк бирү турында Россия Федерациясе хокукый акты яки Татарстан Республикасы хокукый акты басылган көнгə, ə гражданнарга карата –аларны эштəн азат итү турында хокукый акт чыккан көнгə билгелəнгəн вазыйфаи хезмəт хакы (акчалата бүлəклəү) күлəменнəн чыгып түлəнə.

3. Бер тапкыр бирелə торган бүлəклəү күрсəтелгəн затны җирле үзидарəнең тиешле органының хезмəткə түлəү фонды акчалары хисабына бүлəклəү яки бүлəк бирү турында Россия Федерациясе хокукый акты яки Татарстан Республикасы хокукый акты басылган көннəн соң 30 көн эчендə күрсəтелгəн зат муниципаль хезмəт вазыйфасын (муниципаль вазыйфаны) башкара торган яки башкарган җирле үзидарə органы тарафыннан гамəлгə ашырыла.

4. Әлеге карарны Интернет мəгълүмат-телекоммуникация челтəрендə htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мəгълүматының рəсми порталында, Интернет мəгълүмат-телекоммуникация челтəрендə http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рəсми сайтында һəм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвижавылы территориясендəге мəгълүмат стендларында бастырырга.

3. Әлеге карар рəсми басылып чыккан көненнəн үз көченə керə.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы Э.Ю.Игнатьева